**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 10 июнендәге 2025 номерлы карары**

**2026 елның 21 июлендә**
**Казан шәһәрендә хач йөрешен үткәрүдә**
**булышлык итү турында**

Рус Православие Чиркәвенең Казан епархиясе идарәчесе Казан һәм Татарстан митрополиты Кириллның 2026 елның 21 июлендә Благовещение соборыннан Крестовоздвижение чиркәвенә кадәр могҗизалы Казан Изге Ана иконасы белән хач йөрешен үткәрүдә булышлык итү турындагы мөрәҗәгатен карап тикшергәннән соң:

**1. Карар бирәм:**

1.1. транспорт чаралары хәрәкәтенә һәм туктап торуына чикләү кертергә:

1.1.1. 2026 елның 21 июлендә 07:00 сәгатьтән алып, хач йөреше автомобиль юлы буйлап узганнан соң хәрәкәт ачыла торган итеп, түбәндәге юллар буенча:

- Кремль урамы, Чернышевский урамыннан Беренче Май мәйданына кадәрге участокта;
- Профсоюз урамы, Чернышевский урамыннан алып Меңьеллык мәйданына кадәрге участокта;
- Беренче Май мәйданыннан төшү юлы, Кремль урамыннан алып Профсоюз урамына кадәрге участокта;
- Бауман урамы, Профсоюз урамыннан алып Батурин урамына кадәрге участокта;
- Меңьеллык мәйданыннан Батурин урамына чыгу юлында;
- Батурин урамыннан Кремль транспорт дамбасына чыгу юлында;

- Батурин урамы, Кремль транспорт дамбасыннан алып Дзержинский урамына кадәрге участокта;

- К.Маркс урамы, Лобачевский урамыннан алып Батурин урамына кадәрге участокта;

- Япеев урамы, Дзержинский урамыннан алып Большая Красная урамына кадәрге участокта (кирәк булганда);

- Миславский урамы, К.Маркс урамыннан алып Дзержинский урамына кадәрге участокта;

1.1.2. 2026 елның 21 июлендә 07.00 сәгатьтән 09.30 сәгатькә кадәр Большая Красная урамының автомобиль юлы буенча, Япеев урамыннан алып Батурин урамына кадәрге участокта;

1.1.3. 2026 елның 20 июлендә 20:00 сәгатьтән алып 2026 елның 21 июлендә 09:30 сәгатькә кадәр Миславский урамының автомобиль юлы буйлап, К.Маркс урамыннан алып Большая Красная урамына кадәрге участокта (транспорт куюны тыеп);

1.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров):

1.2.1. хач йөреше маршруты буенча юл хәрәкәтен оештыруда техник чараларны каплау һәм ачу, сүтү эшләрен башкаруны тәэмин итәргә;

1.2.2. транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турындагы мәгълүматны Интернет челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми порталы» дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырырга;

1.2.3. кыска вакытлы аренда хезмәте күрсәтүче электр самокатлары (WHOOSH һәм МТС.URENT) һәм велосипедлар («Яшел шәһәр») операторлары белән берлектә әлеге карарда күрсәтелгән участокларда шәхси мобильлек чараларын куеп торуны һәм аларның хәрәкәтен тыю эшен оештырырга;

1.3. «Шәһәр парковка урынын оештыручы» муниципаль казна учреждениесенә (И.Б.Тихонов), кертелә торган чикләүләрне исәпкә алып, муниципаль парковкалар өчен түләүне контрольдә тоту буенча автомобиль хәрәкәте маршрутын үзгәртергә;

1.4. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (А.М.Шайнуров) Казан шәһәре Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе (А.И.Салихов) белән берлектә юлларны йөк техникасы яки таранга каршы блоклар белән ябу эшен оештырырга;

1.5. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**2. Тәкъдим итәм:**

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Р.Д.Габитов) әлеге карар нигезендә Казан шәһәре урам-юл челтәренең югарыда күрсәтелгән участокларында юл хәрәкәте иминлеген саклауны һәм оештыру-көйләү гамәлләрен башкаруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

2.2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Казан шәһәре буенча Сәламәтлек саклау идарәсенә (И.М.Әхмәдиев) хач йөрешендә катнашучыларга медицина хезмәте күрсәтүне тәэмин итәргә;

2.3. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) урам-юл челтәренең күрсәтелгән участокларында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләүне кертү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе Б.Р.Алиевкә **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**